Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«13» ноябрь 2020 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2020 елның 13 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы территориясендә яшәүче I төркем инвалидларыннан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме

- Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау;

- янгыннан саклау өчен җиһаз сатып алу» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 238 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 150 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 139 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 11 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныирга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы территориясендә яшәүче I төркем инвалидларыннан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме

- Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау;

- янгыннан саклау өчен җиһаз сатып алу» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Р.Г. Хисамов

Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов